ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТУРИЗМУ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТУРИСТЛЫК БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

20.09.2024 Казан ш. № 194

Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетының «Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетында дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе турында нигезләмә раслау турында» 2023 елның 13 октябрендәге 207 номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Президентының «Федераль дәүләт хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссияләре турында» 2010 елның 1 июлендәге 821 номерлы Указына үзгәрешләр кертелүгә бәйле рәвештә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетының «Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетында дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе турында нигезләмә раслау турында» 2023 елның 13 октябрендәге 207 номерлы боерыгына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге боерык белән расланган Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетында дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе турында нигезләмәдә:

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Комиссиянең төп бурычы булып Дәүләт комитеты тарафыннан түбәндәгеләргә ярдәм итү тора:

а) Дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең (алга таба – дәүләт хезмәткәрләре) мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмый калу яисә җайга салу турында чикләмәләрне һәм тыюларны, таләпләрне үтәвен тәэмин итүдә, коррупциягә каршы тору максатларында алар

тарафыннан «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы федераль законда, башка федераль законнарда билгеләнгән бурычлар үтәлешен (алга таба – хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм (яисә) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу) тәэмин итүдә;

б) Дәүләт комитетында коррупцияне кисәтү буенча чараларны гамәлгә ашыруда.»;

15 пунктны түбәндәге эчтәлектәге «е» пунктчасы белән тулыландырырга:

«е) дәүләт хезмәткәренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәүгә һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салуга комачаулаучы, аңа бәйле булмаган шартлар барлыкка килүе турында хәбәр итүе.»;

в) 19.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«19.1 Әлеге Нигезләмәнең 15 пунктының «б» пунктчасындагы бишенче абзацта һәм «е» пунктчасында күрсәтелгән белдерүләр Дәүләт комитетының кадрлар һәм юридик эш бүлегенең коррупциячел һәм башка төр хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы булган вазыйфаи заты тарафыннан карала, ул белдерүләрне карау нәтиҗәләре буенча нигезләнгән бәяләмә әзерли.»;

г) 19.2 пунктында «15 пунктның «д» пунктчасында» сүзләрен «15 пунктның «д» һәм «е» пунктчаларында» сүзләре белән алмаштырырга;

д) 19.3 пунктында:

«а» пунктчасында «15 пунктның «д» пунктчасында» сүзләрен «15 пунктының «д» һәм «е» пунктчаларында» сүзләре белән алмаштырырга;

«в» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«в) Нигезләмәнең 15 пунктындагы «б» пунктчасының икенче һәм бишенче абзацларында, «д» һәм «е» пунктчаларында күрсәтелгән мөрәҗәгатьләрне яисә хәбәрләмәләрне беренчел карау нәтиҗәләре буенча нигезләнгән нәтиҗә, шулай ук әлеге Нигезләмәнең 28, 30.1, 33, 33.1 пунктлары нигезендә карарларның берсен яисә башка төрле карарны кабул итү өчен киңәшләр»;

22 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Нигезләмәнең 15 пунктының «д» һәм «е» пунктчаларында күрсәтелгән белдерүләр, кагыйдә буларак, Комиссиянең чираттагы (планга кертелгән) утырышында карала.»;

23 пунктта «15 пунктның «б» пунктчасы белән» сүзләрен «15 пунктның «б» һәм «е» пунктчалары белән» сүзләренә алмаштырырга;

23.1 пунктның «а» пунктчасында «15 пунктның «б» пунктчасы белән» сүзләрен «15 пунктның «б» һәм «е» пунктчалары белән» сүзләренә алмаштырырга;

32 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«32. Нигезләмәнең 15 пунктының «а», «б», «г», «д» һәм «е» пунктчаларында күрсәтелгән мәсьәләләрне карау йомгаклары буенча, моңа нигезләр булган очракта, комиссия Нигезләмәнең 26-31, 33, 33.1 пунктларында каралганнан башкачарак карар кабул итә ала. Мондый карар кабул итүнең нигезләре һәм мотивлары Комиссия утырышы беркетмәсендә чагылдырылырга тиеш.»

түбәндәге эчтәлекле 33.1 пунктын өстәргә:

«33.1 Нигезләмәнең 15 пунктының «е» пунктчасында күрсәтелгән мәсьәләне карау йомгаклары буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) дәүләт хезмәткәренә бәйле булмаган шартларның барлыкка килүе һәм аларның хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәүгә һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салуга мөмкинлек бирмәве арасында сәбәп-нәтиҗә бәйләнеше булуын танырга;

б) дәүләт хезмәткәренә бәйле булмаган шартларның барлыкка килүе һәм аларның хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәүгә һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салуга мөмкинлек бирмәве арасында сәбәп-нәтиҗә бәйләнеше булмавын танырга.»;

әлеге боерык белән расланган Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетында дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе составында:

комиссия составыннан чыгарырга:

Гущенкова Аделина Максимовнаны,

комиссия составына кертергә:

Воробьева Елена Владимировнаны – Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетының кадрлар һәм юридик эш бүлегенең әйдәп баручы консультантын, комиссия секретарен.

2. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Рәис С.Е. Иванов